IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ LVIII УТЫРЫШЫ

КАРАР

21 февраль 2025 ел №95

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы авыл җирлегенең «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» «28» ноябрь 2018 елның 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Россия Федерациясе Салым кодексына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» «28 » ноябрь 2018 елның Метрәй номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 3.2 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата салым ташламасы бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2_1 бүлегендә урнашкан урыннар моңа керми.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Метрәй Авыл җирлеге башлыгы Шамгунов И.В.